**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №130-16 "14" апрель 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2008 елның 22 сентябрендәге 203-28 номерлы карары белән расланган, «Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (25.12.2008 №231-33, 23.07.2009 №289-39, 11.12.2009 №306-42, 11.11.2010 №5-2, 20.04.2011 №42-8, 22.10.2013 №264-37, 12.08.2014 №314-45, 21.10.2015 №10-2, 09.11.2017 №152-22, 20.08.2019 №273-38, 22.10.2019 №289-39, 12.03.2020 №325-45, 16.06.2020 №352-47, 14.12.2020. №21-3, 26.08.2021 №66-9, 26.10.2021 №84-11 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2021 елның 29 11 декабрендәге 384-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында"Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2008 елның 22 сентябрендәге 203-28 номерлы карары белән расланган, «Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турында» Нигезләмәгә (25.12.2008 №231-33, 23.07.2009 №289-39, 11.12.2009 №306-42, 11.11.2010 №5-2, 20.04.2011 №42-8, 22.10.2013 №264-37, 12.08.2014 №314-45, 21.10.2015 №10-2, 09.11.2017 №152-22, 20.08.2019 №273-38, 22.10.2019 №289-39, 12.03.2020 №325-45, 16.06.2020 №352-47, 14.12.2020. №21-3, 26.08.2021 №66-9, 26.10.2021 №84-11 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унберенче абзац өстәргә: «гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;

б) унберенче - ундүртенче абзацларны уникенче - унбишенче абзацлар дип санарга;

2) 14.5 статьясындагы 2 пунктында «җирле бюджет кытлыгы,» сүзләреннән соң «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган өлеше күләменнән тыш,» сүзләрен өстәргә;

3) 31 статьяның дүртенче өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

4) 33 статьяның 3 пунктында «әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексында башкасы каралмаган булса.» сүзләрен өстәргә.

2. «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда веб-адрес буенча әлеге карарны бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм веб-адрес буенча Азнакай муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай район Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин